ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2020 ел Баулы шәһәре №248

Баулы муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 11 мартындагы
58 номерлы карары белән
расланган «2019-2023 елларга
Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында
кече һәм урта эшкуарлыкны
үстерү» муниципаль программасына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 маддәсенең 2нче часте, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 11 мартындагы 58 номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

программаның I «Муниципаль программа паспорты» бүлегендә «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлында 2нче баганаының эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаны гамәлгә ашыруга финанс чаралары ихтыяҗы 38 909,9 мең сум (җирле бюджет акчалары) тәшкил итә, еллар буенча түбәндәгечә бүлгәләнгән: 2019 ел - 15 683,5 мең сум; 2020 ел - 5 806,6 мең сум; 2021 ел - 5 806,6 мең сум; 2022 ел - 5 806,6 мең сум; 2023 ел - 5 806,6 мең сум.»;

Программага 2нче «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасының төп чаралары исемлеге” кушымтасында 3нче «КУЭ субъектларына финанс ярдәме чараларын гамәлгә

ашыру» пунктында 5нче багананың эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Республика бюджеты, җирле бюджет - 38 909,9 мең сум».

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 11 мартындагы 58 номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 8 октябрендәге 286 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И.Гозәеров